وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№21 (164). 23 ноябрь 2012 / 9-мөхәррәм-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Оҗмах – аналарның аяк астында ▷2-3◁



Ислам мәдәниятендә Алтын Урда сәнгате ▷3-4◁



Сөйләм әдәбе ▷4◁

# Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәизнең ИСТАНБУЛДАГЫ VIII Евразия ислам съездында ясаган чыгышы



**Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!**

*Еллар үткән саен тарих та үзгәрә бара. Гасырлар арасында гына түгел, берничә дистә ел эчендә дә вакыйгаларның башка юнәлеш алуын күрә алабыз. Хәзерге россиялеләр билгеле бер дәүләттә тусалар да, үзләренең тормышларын башка мохиттә, ягъни элеккеге чикләр шартлылыкка әйләнгән, барысы да дөнья стандартлары белән үлчәнгән җәмгыятьтә корырга мәҗбүрләр. Глобальләшү тормышның һәр өлкәсенә дә, шул исәптән рухи дөньябызга да үзенең төзәтмәләрен кертеп килә.*

*Динебез һәм мәдәниятебез ярдәмендә оешкан рухи асылыбыз ата-бабаларыбыздан калган тарихи үзенчәлекне һәм татар халкының үзгә менталитетын билгеләп килде. Бүген исә ислам динен һәм татарларның милли мәдәниятен берләштергән идеалларга - бер мәдәниятkә генә кайтып калган мохиттә югалу куркынычы яный, ә бу үз чиратында милләтебезнең рухи нигезләрен какшатуга һәм адәм балаларының шәхси үзенчәлекләренең гоуммассада эреп югалуына китерә.*

*Ислам өчен этник чикләүләр юк, ул - дөньякүләм дин, шул ук вакытта ислам тәгълиматы кешенең милли үзаңына да тискәре йогынты ясамый. Аллаһы Тәгалә безне халыклар һәм кавемнәр итеп яралткан, һәр халыкны үзләренә генә хас булган сыйфатлар белән бүләкләгән. Тарихтан билгеле булганча, ислам дине еш кына милләтләрне берләштерүче бер көч буларак яшәп килде, мисалга, төрки милләтләрне генә алыйк. Инде ничә гасырлар дәвамында ислам дине татарларның аерылгысыз бер рухи кыйбласы ролен үтәде, шуңа да халкыбыз бер гасырга сузылган атеизм чорында да үзенең рухи кыйммәтләрен югалтмады. Хәнәфи мәзһәбе аркылы җиткерелгән ата-бабаларыбыз һәм пәйгамбәрләребез (аларга Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) динен үстерү, ныгыту өстендә эшләү безнең төп максатыбыз булырга тиеш.*

*Бер караганда, бүгенге көндә дини һәм мәдәни гореф-гадәтләребезне иркен рәвештә үти алабыз кебек, шулай да безгә чит булган дини агым-юнәлешләрне көчләп тагу белән дә еш очрашырга туры килә. Бу күренеш демократик җәмгыять принципларына, гомумән, туры килми. Социологлар раславынча, XXI гасыр - хәвеф-хәтәрләр җәмгыяте, ләкин алар моның төп сәбәбен бары тик җәмгыятьтәге икътисади һәм сәяси үзгәрешләргә генә кайтарып калдыра. Безгә янаган иң зур куркыныч, минемчә, - рухи кыйммәтләребезнең җимерелүендә. Ислам - дини төшенчәләр белән аңлатылган гыйбарә генә түгел, ә, иң беренче чиратта, җәмгыятебездәге һәр кешенең шәхсән үсеше, үзара мөнәсәбәтләребезнең нигезе һәм дәүләтне оештыра алырдай көч. Шуңа да бүген безгә дини һәм мәдәни кыйммәтләребезне саклап калу юлында эшләргә кирәк, шул очракта киләсе буыннарның рухи үсеше өчен дә ныклы җирлек булачак.*

*Бүгенге көнебез, яшәешебез иртәгесе көндә тарих битләренә язылачак, шуңа аның ничек-нинди булуы өчен барыбыз да җаваплы. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә дә иң хәерлесен, файдалысын гына бирә. Аның биргәннәрен тиешенчә кабул итәбезме, дөрес кулланабызмы соң? Без булганны җимереп һәм көч кулланып тәртип урнаштырырга теләгәннәр кебек түгел, киресенчә, рухи үсеш юлында хезмәт итәргә тиешбез. Чөнки бары тик шул юл белән генә Аллаһы Тәгалә адәм балаларына кушып калдырган тынычлык һәм татулыкка ирешә алачакбыз.*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### "ШӘМАИЛ ҺӘМ ИСЛАМ АРХИТЕКТУРАСЫ" БӘЙГЕСЕ ТӘМАМЛАНДЫ

**Рамазан аеннан соң Чирмешән районының барлык сәнгать мәктәпләрендә дә "Шәмаил һәм ислам архитектурасы" дип исемләнгән бәйге игълан ителгән иде.** 21 ноябрь көнне Чирмешән мәчетендә әлеге конкурска нәтиҗәләр ясалды.

Бәйгегә егермедән артык рәсем, аппликацияләр, чигелгән шәмаилләр тәкъдим ителгән. "Катнашучыларның барысына да истәлекле бүләкләр, җиңүчеләргә һәм бәйгене оештыручыларга призлар һәм дипломнар тапшырылды", - дип хәбәр иттеләр район мөхтәсибәтеннән.

Бәйгедә катнашучылар өчен якшәмбе мәктәбенә йөрүче укучылар тарафыннан бәйрәм табыны әзерләнгән. Чәйдән соң Хәбир хәзрәт Ханов "Балалар тәрбиясе рухи-әхлакый тәрбиядән башлана" дигән темага вәгазь укыган.

Конкурсның йомгаклау тантанасында балалар, аларның әти-әниләре, якшәмбе мәктәбе шәкертләре, мәхәллә халкы һәм мәчет кунаклары катнашкан, аларның саны йөздән артып киткән.

### МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕН ҺӨНӘР САЙЛАРГА ӘЗЕРЛИЛӘР

**"Зәкят" хәйрия фонды мәхәлләгә йөрүче мөселманнарның балалары һәм Казан шәһәренең ятимнәр йортларында тәрбияләнүче сабыйлар өчен һөнәр сайлау юнәлешендә дәресләр үткәрә.**

Әлеге әһәмиятле эшне Исхак хәзрәт исемендәге Милләтара мәдәни-агарту үзәге 2008 елда башлап җибәргән иде. Һәр шимбә һәм якшәмбе көннәрендә "Зәкят" фонды волонтёрлары балаларны каллиграфия серләренә һәм кул эшләренә өйрәтә.

Үткән якшәмбедә балаларны балчык белән эшләргә өйрәттеләр. Дәресләр вакытында, мәхәллә халкы ярдәме белән, чәй табыны да әзерләнде. Әлеге изге гамәлгә үзләренең өлешләрен кертергә теләүчеләр Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фондына мөрәҗәгать итә ала.

### "БЕР АЙ ЭЧЕНДӘ МИЛЛИОН" АКЦИЯСЕ ТӘМАМЛАНДЫ

**Түбән Камада мәчет төзелеше өчен оештырылган "Бер ай эчендә миллион" акциясе тәмамланды. Акция ярдәмендә барлыгы 950 мең сум акча җыелды.**

Акцияне оештыручылар: "Акча җыю төп максат түгел иде, теләгебез - кешеләргә игелекле гамәл кылырга мөмкинлек тудыру һәм Гагарин урамындагы мәчет төзелешен активлаштырып җибәрү иде", - диләр. Әлеге максатларга тулысынча ирешелгән.

Хәзерге вакытта манараны күтәрү буенча колачлы эш алып барыла: кирпеч корылмалары һәр көн диярлек үсә, айны әзерләү буенча оешмалар белән сөйләшүләр бара.

Сүз дә юк: мәчет төзелешенә акция дәвамында җыелган акча гына җитеп бетми, шуңа да Аллаһ йортын төзү өчен башкалар да кушыла ала.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# 24 ноябрь — Гашура көне

***Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил галәмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһи әҗмәгыйн. Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!***

Аллаһның рәхмәте белән 15 ноябрьдә һиҗри белән 1434 нче ел башланып китте. Аның беренче ае - мөхәррәм һәм аның унынчы көне - Гашура көне. Гашура (гарәпчә "гашәрә") "ун" дигән сүз. Нәрсәсе белән истәлекле соң бу көн, ни өчен без аны шулай зурлыйбыз?

Исламияттә һәм башка диннәр тарихында Гашура көне бер мөбарәк көн буларак кабул ителгән һәм бу хакта күп кенә риваятьләр сөйли.



Җир вә күкләрне, оҗмахны Аллаһ шушы көндә яралткан.

Гашура көнендә Аллаһы Тәгалә гарше көрсине, кәләмне яралткан, барча олуг фәрештәләрне бар кылган.

Адәм галәйһиссәләмнең тәүбәсе Гашура көнендә кабул булган.

Гашура көнне Идрис галәйһиссәләм җәннәткә кертелгән.

Исраил уллары бу көнне Фиргавеннең золымыннан котылып, шушы көннән ураза тота башлаганнар. Мөселманнар да, рамазан уразасы фарыз булганчы, бу айда ураза тотканнар. Рамазан уразасы фарыз булгач, Гашура көнендәге ураза һәркемнең үз ирегенә калдырылган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) бу көннәрдә ике көн ураза тоткан һәм аны өммәтенә дә васыять итеп калдырган.

Бу көнне Нух пәйгамбәр көймәсе туфан суыннан котылып, Җүди тавына килеп туктаган.

Бу көнне Ягъкуб пәйгамбәр үзенең улы Йосыф пәйгамбәр белән кавышкан.

Гашура көнендә Юныс пәйгамбәр балык карыныннан котылган.

Шушы көндә Ибраһим пәйгамбәр Нәмруд патшаның утыннан исән-имин чыккан.

Тагын да килеп, Әюб пәйгамбәр 18 ел авырганнан соң тәнендәге кортларыннан котылган.

Гашура көнендә Давыд галәйһиссәләмнең тәүбәсе кабул ителгән, Сөләйман пәйгамбәргә патшалыгы кайтарылган, Гайсә пәйгамбәр шушы көнне туган һәм күккә алынган.

Болардан башка да бу көнне бик күп изге гамәлләр кылынуы турында риваятьләр сөйләнә.

Менә шушы гамәлләргә таянып, мөселманнар бу көнне зурлап, ураза тотып, изге гамәл-гыйбәдәт кылып үткәрәләр.

Гашура көнендә пәйгамбәребезнең оныгы Хөсәен вәхшиләр кулыннан һәлак ителгән. Аның белән бергә башка бик күп сәхабәләр шәһит кылынган.

Мөхтәрәм җәмәгать! Пәйгамбәребезнең (сгв) сөннәтен үтәп, шушы көнне ураза тотып, изге гамәлләр кылып үткәрсәк, Аллаһка якынаербыз, гөнаһларыбыз кимер һәм Кыямәт көнендә Пәйгамбәребезнең (сгв) шәфәгатенә лаек булырбыз.

Гашура көне һиҗри исәп буенча ел башына туры килә: аны нинди гамәл белән каршы алсак, елыбыз да шулай үтәр. Аллаһы Тәгалә һәрбарчабызга хәерле гамәлләр кылырга насыйп әйләсә һәм Аның рәхмәтенә ирешүне насыйп итсә иде.

*Җәүдәт хәзрәт ХАРРАСОВ, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Президиум әгъзасы, Тукай районы имам-мөхтәсибе*

# 2012 елгы хаҗ сәфәре югары дәрәҗәдә узды

**Стататистика буенча, ел саен Татарстаннан төрле туроператорлар аркылы 1200-1300 кеше хаҗга китә. Быел да хаҗилар саны буенча күрсәткечләр алдагы еллардан калышмады. Сәфәр тиешле дәрәҗәдә узсын өчен барлык чаралар да күрелде. Бу турыда агымдагы елның хаҗ сәфәре нәтиҗәләренә багышланган пресс-конференциядә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең халыкара мөнәсәбәтләр бүлеге һәм "ДУМ РТ Хадж" программасы җитәкчесе Хәбибулла Нәфисуллин хәбәр итте.**




Быелгы хаҗны аккредитация узган "Хезмәт-тур" һәм "ДУМ РТ Хадж" туроператорлары оештырды. Беренче туроператор аша - 500, ә икенчесе аркылы Татарстан, шулай ук Сембер, Самара һәм башка өлкәләрдә яшәүче мең мөселман кешесе юллама алды.

- Россиянең башка төбәк мөфтиләре үз хаҗиларын Татарстан туроператорлары аша җибәрергә теләп мөрәҗәгать итә. Аларны вәгазьләр, татар-милли компонентларын саклый торган материаллар таратыла, хаҗны үз дине һәм милләте кешеләре белән бергә кылу җәлеп итә, - диде Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең аппарат җитәкчесе Ришат Хәмидуллин.

Оештыручылар һәм хаҗилар сүзләреннән аңлашылганча, агымдагы ел хаҗы югары дәрәҗәдә үткән.

- Барлык планнар да үтәлде, алга куелган максатларга ирешелде, күпмедер дәрәҗәдә хәтта алдан уйланмаган һәм сөйләшенмәгән шартлар да яхшыртылды, - дип ассызыклады хәзрәт.

Яңа оешма барлыкка килгәннән соң, хаҗга бару бәясе 30 процентка очсызрак булуы хакында сүз дә булды - программа җитәкчесе сүзләренә караганда, Мәккәгә бару шартлары VIP-статуска туры килгән, башка туроператорлар куйган бәя белән чагыштырганда, 20-30 процентка арзангарак төшкән.

Хаҗга төрле VIP-програмаларда бару, оештыручыларның исәпләве буенча, 150-180 мең сумга төшә. Беренче төркем белән хаҗга китәргә теләк белдерүчеләргә юллама 98-108 мең сумга туры килгән. Соңрак, барырга теләүчеләр аларны 122 меңнән 144 мең сумга кадәр ала алган. Оештыручылар сүзләренә караганда, бәяләрнең төрле булуы салым тарифларының артуы һәм доллар курсының күтәрелүе белән бәйле.

Хәбибулла хәзрәт Нәфисуллин сүзләренә караганда, хаҗны оештыру шактый уңайлы һәм уңышлы булган. "Казаннан туп-туры Мәдинәгә оча торган авиарейслар оештырудa да уңыш елмайды. Ул гына да түгел, сәфәр алдыннан без Казанда һәм республикабызның төрле районнарында хаҗга әзерлек буенча лекцияләр үткәрдек. Дин сабаклары шулай ук Мәккәдә дә оештырылды", - дип өстәдә оештыручы.

Мәдинәдә хаҗилар Әл-Хәрам мәчетеннән 100-150 метр ераклыкта гына урнашкан 4-5 йолдызлы кунакханәләрдә яшәгәннәр. Аларны ашату өчен бушлай "швед өстәле" оештырылган.

- Әлеге мәсьәлә алдан хәл ителмәгән иде, бу елдан-ел хаҗилар өчен зур проблема булып тора. Мәккәдә "швед өстәле" баштa түләүле иде, әмма соңыннан без пенсия яшендәге барлык хаҗиларны бушлай ашату турында карар кабул иттек. Хаҗиларның күпчелеге Татарстаннан - шактые пенсия яшендә, - дип сөйләде Хәбибулла Нәфисуллин.

Мәдинә буенча түләүсез экскурсия дә планга кертелмәгән була. Хаҗ кылыр алдыннан хаҗиларга Гарәфә үзәнен күрсәткәннәр, Коръән аятьләре беренче булып иңгән тауларга да алып менгәннәр.

- Әл-Хәрам мәчетеннән кунакханәгә кадәр туннель аша йөри торган автобуслар оештыра алуыбызны да зур уңыш, дип саныйм. Чөнки җир өсте транспорты белән барган очракта 800 метр җәяү барырга туры килгән булыр иде. Быелгы хаҗның тагын бер үзенчәлекле ягы күзәтелде: татар халкының барлык гореф-гадәтләрен истә тотып, корбан ашы оештырылды. Хаҗилар арасыннан булган Коръән-хафизлар Коръән укыдылар. Мәккәдә хаҗ кылган арада Изге Китапны тулысынча укып чыктылар, - диде Хәбибулла хәзрәт.

- Согуд Гарәбстаны да Татарстанның хаҗ сәфәрен тиешле дәрәҗәдә оештыруын бәяләде: Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә үзенең рәхмәтен җиткерде һәм Әл-Хәрам мәчете төшкән бүләк тапшырды, - дип билгеләп үтте Ришат Хәмидуллин.

***"Islam today" мәгълүмати-аналитик федераль порталы***

25 НОЯБРЬ - ӘНИЛӘР КӨНЕ

# ОҖМАХ – АНАЛАРНЫҢ

**Һәр мөселман да Коръәннең һәр аятен, һәр хәрефен ихлас күңелдән тоярга һәм күңеленнән кичерергә тиеш. Чөнки мөэмин-мөселманнар тормышының төп мәгънәсе, чынбарлыкта, шуннан гыйбарәт тә. Динебездә "Ана кеше" дигән бөек затка никадәр әһәмият бирелүе турында аятьләрдә һәм хәдисләрдә күп әйтелгән.**

Аллаһы Тәгалә Изге Коръәндә (мәгънәсе): ***"Без кешегә: ата-анаңа игелекле бул, дип васыять иттек. Анасы аны нинди кыенлыклар белән карынында йөртә. Ике ел буе сөтеннән аермаенча имезеп үстерә. Бәс, иң башта Миңа, аннан соң ата-анага шөкер ит, дип васыять иттек. Кайтарылыш бары тик Миңа гына булыр" ("Локман" сүрәсенең 14 нче аяте)***, - дип мөрәҗәгать итә.

Бервакыт бер ир кеше пәйгамбәребез Мөхәммәдтән (сгв) аны хәрби походка алуын сорап мөрәҗәгать иткән. Аллаһның рәсүле (сгв) аннан, аның әнисе бармы икәнлеге белән кызыксынган. Тегесе уңай, бар дип җавап биргәч, әйткән: ***"Аның янында кал, чөнки оҗмах - аналарның аяк астында" (Әхмәд, әл-Насаи)***, - дигән.

Әйтелгән бу сүзләрнең никадәр тирән, зур эчтәлекле икәнен күз алдына китерегез әле сез! Нинди дулкынландыргыч күренеш күз алдына килә: бер-берсенә чиксез сөю һәм рәхмәтле караш белән баккан әни кеше һәм аның нарасый баласы, газиз сабыеның нәни генә учлары - әнисенең кайгыртучан җылы кулларында... Әни кеше һәрвакыт та әни кеше булып кала, бәхет-шатлыкларда да, хәсрәт-кайгыларда да. Оҗмах - аналарның аяк астында, ул оҗмах капкалары һәркемгә дә ачык, әниләренең кадерен белгән, хөрмәт иткән һәм аларның фидакарь хезмәте һәм чиксез сөюләренә тиешле бәя биргәннәрнең барсына да ачык ул ишек.

Аллаһы Тәгалә әни кешеләргә күпме вазифа һәм бурычлар йөкләгәнен күз алдына китерегез. Ул сабыр да булырга тиеш, диндар да булырга. Үз баласын да яратырга, балаларының күңелләрен хак иманда, аларны ислам нурында үстерер өчен Аллаһы Тәгаләгә итагать итәргә дә тиеш. Чын мөселман хатын-кызы шуларны истә тотарга тиеш:

● Бала көткәнен белгән хатын-кыз, Аллаһның олуг бу мәрхәмәте өчен Аңа шөкер итеп, рәхмәт әйтергә тиеш.

● Әни кеше, беренче бәбиен табып, аңа караганчы: "Ий Аллаһ! Безгә диндар балалар бүләк итеп, хәер-фатихаңны бир, Син безнең догаларны ишетсәң һәм аларга игътибар итсәң бит!" - дип, шатланып әйтергә тиеш.

● Әни булачак кешеләр, булачак бу олуг бүләк өчен, авырлы булу һәм бала табу белән бәйле булган бар авырлыкларны да сабыр кичерергә тиешләр.

● Күп балалы әниләр - сөю хисле һәм кайгыртучан булырга тиешләр.

● Алар үз балаларын ныклы иман рухында һәм аларда югары әхлак сыйфатлары һәм күркәм холык тәрбияләргә катгый карарга килгән әниләр булырга тиешләр.

● Алар үз балаларына бар яктан да үрнәк әниләр булырга тиешләр. Үзе вафат булганнан соң, аның балалары аның күркәм тәрбия биргәнә, зирәк киңәшләренә, аларга дини һәм дөньяви тәрбия бирү өчен катгыйлыгына рәхмәтле булырлык булсын.

● Алар үз ирләре белән бергә, үз тормышларын Исламның бер өлеше иткән, иренә итагать итеп, шуның белән аны бәхетле иткән, һәм дә шул гамәле белән Аллаһка да итагать иткән аналар булырга тиешләр.

Күп кешеләр бала бүләк итүен сорап гомерләре буе Аллаһка ялваралар. Тик Аллаһ башкача хөкем йөртә.

Бала көткәнен белгән хатын, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт юлларга тиеш, чөнки бу, чынлап та, олуг бүләк. Аллаһның бөек пәйгамбәрләреннән берсе Ибраһим галәйһиссәләм йөз ел буе Аллаһтан бала бирүен ялварган. Шулай ук Зәкәрия галәйһиссәләм олыгайган көннәрендә Аллаһтан бала бүләк итүне үтенеп сораган. Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) балалары бары тик беренче хатыны - Хәдичәдән генә булган. Ирәтлар хатыннары бала көткәндә, булачак малай туу турында шундый бер дәрт белән хыялланa башлыйлар, ир бала урынына кыз бала туса, кәефләре кырыла яки моны, гомумән, зур кайгы төшкән кебек итеп кабул итәләр. Мөселман хатын-кызлары болай эшләмәскә тиешләр. Кызлар - алар ата-аналарының бу дөньяда да, ахирәт хозурында да күз нурлары. Аллаһы Тәгалә Изге Китапта: ***"Күкләр һәм Җир - Аллаһның милке. Үз теләгәнен бар итәр. Теләсә - кыз балалар бирә, теләсә - ир угланнар бүләк итә" ("Шура (Киңәш)" сүрәсенең 49 нчы аяте)***, - дигән.




Аллаһы Тәгалә бу аятьтә, кыз-балаларны алдан әйтеп киткән. Аллаһ, кешегә ни генә бүләк итмәсен, барысы да аның файдасына гына. Шуңа да, мөселман хатын-кызлар, Аллаһның бар биргәненә дә, аның өчен, биргән бөек бар бүләкләре өчен рәхмәтле булырга тиешләр. Моны шундый дога укып башкарырга була: ***"Ий Аллаһым! Сиңа, Синең бирүзеңә генә (мине аналык бәхете мәртәбәсенә лаек иткәнең өчен) минем бар мактауларым, минем бар рәхмәтләрем!"***

Аллаһы Тәгалә аналарны хөрмәт итә, аларга, әтиләребезгә итагать иткән кебек үк итагать итәргә куша, бала көтү, балаларны тәрбияләп үстерү белән бәйле булган катлаулыклар аркасында, аның дәрәҗәсен Ул югарырак да күтәргән.

Коръән балалар табып, аларны тәрбияләп үстерүдә аналарның гаять зур роле турында сөйли. Үсеп килүче буынга тәрбия бирү - иң мөһиме, чөнки ул - безнең киләчәгебез. Балаларга тәрбия бирүнең мөһимлеген Изге Коръәндәге күп сандагы аятьләр һәм Пәйгамбәрбезнең (сгв) хәдисләре дәлилли. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: ***"Әй, иманлы бәндәләр, утын урынына кешеләр һәм ташлар ягылган җәһәннәмнән үзегезне һәм гаиләгезне саклагыз. (Җинаятьчеләрне) кызгана белми торган, көчле һәм Ал-***

# Ислам мәдәниятендә Алтын Урда сәнгате

**Көнчыгыш Европада ислам мәдәнияте һәм сәнгатенең гөрләп чәчәк атуы мәшһүр Алтын Урда империясе чорына туры килә. Ислам дине Алтын Урдада бер дәүләткә берләштерелгән барлык төрки-татар халкының идеологиясе һәм рухи нигезе булып тора.**





Алтын Урда дәүләтләре - Идел буе Болгарстаны, Кырым, Харәземдә гомумислам мәдәниятенең бер өлеше булган бөек цивилизация барлыкка килә. Аларда җирле халыкларның мәдәният казанышлары бу империянең Ислам кыйммәтләрен үзләштергән үзенчәлекле мәдәнияте белән симбиоз рәвешендә берләшә. Шуның нәтиҗәсендә, Алтын Урдада мөселман мәдәниятенең төрле җирлеккә бәйле төрләре барлыкка килә.

Алтын Урда мәдәниятенең башлангыч чорына Көнчыгыш Азия традицияләренең үтеп керүе хас. Ә XIII гасыр ахыры - XIV гасыр башында дала күчмә халыкларының мәдәниятендә тамыр җәйгән бу традицияләр, Алтын Урданың Болгар, Иске һәм Яңа Сарайлар, Солхат (Иске Кырым), Харәзем кебек үзәк шәһәрләрендә чәчәк аткан мөселман сәнгатенең көчле йогынтысын кичерә. Алтын Урдада рәсми рәвештә кабул ителгән ислам дине, чынбарлыкта, элеккерәк вакыттан ук бай ислам мәдәниятенең традицияләренә ия булган Идел Болгарстаны һәм Харәземнең шифалы йогынтысы аркасында гына өстенлек алуга ирешә һәм әкренләп аның мәдәнияте Исламның эстетик доктринасы даирәсенә керә.

Җир эшкәртү һәм шәһәр цивилизациясенә ия Болгар һәм Харәзем осталары Алтын Урдада мәдәният, мәгъмурият һәм һөнәрчелек үсешендә аерым бер роль уйнаганнар. Алар, урта гасырлар мөселман мәдәниятенең алгарыштагы бар казанышларының таралыш алуында, шәһәр һәм дала халкы зәвыкларының синкретик берләшмәсен тәшкил иткән Алтын Урда империя сәнгате барлыкка килүдә катнашалар. Әлеге дәүләттә бу сәнгатьнең эчтәлеге, нигездә, мөселман мәдәниятенең сәнгати-эстетик принципларын үзләштергән югары катламнарының зәвыклары белән билгеләнә. Аның йогынтысы нәтиҗәсендә Алтын Урда сәнгате яңа баскычларга күтәрелә, мәгъмурият, таш пластикасы (уерып киселгән бина бизәкләре, каберташлар), зәргәрчелек сәнгате (алтын, көмеш һәм асылташлардан бизәнү әйберләре), металлны сәнгатьчә эшкәртү (тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары), керәч (керамика: савыт-саба, биналарны бизәкли торган керәч такталар (чинтакталары)) зур үсеш алалар.

Сәлҗукләр яшәгән Кече Азия, мәмлүкләр Мисыры, Сүрия, Иран кебек мөселман илләре белән тыгыз сәяси, сәүдә һәм мәдәни мөнәсәбәтләрдә тору аларның сәнгате һәм мәгъмурияты өчен хас булган элементларның Алтын Урда мәдәниятенә үтеп керүенә ярдәм итә. Кече Азия, шул исәптән сәлҗук төркиләре сәнгате тәэсире Кырым аша, Урта Азия сәнгате йогынтысы Харәзем һәм Хивә аркылы үтеп керә. Бу Болгар, Солхат (Иске Кырым), Чуфут Калә (Кырык-Ер), Иске йорт (Бакчасарай), Үргәнч һәм Алтын Урданың башка шәһәрләрендә бүгенге көнгә кадәр сакланып калган биналар мәгъмуриятында ачык чагылыш тапкан. Шул ук вакытта, киресе дә күзәтелә, мәсәлән, Алтын Урда төрки-татар мәдәнияте йогынтысы мәмлүкләр Мисыры сәнгатендә чагылыш алган.

Алтын Урданың Идел буе шәһәрләре таш һәм кирпечтән эшләнгән биналарның күплеге, аларда кулланылган төзелеш материалларының, мәгъмурият элементларының, бизәү алымнарының күптөрлелеге белән аерылып торалар. Алтын Урда мөселман сәнгатенә хас булган үзенчәлекләр Идел буе Болгарстаны мәркәзе һәм Алтын Урданың, Җучи ханнарының "алтын тәхете" исемен алган беренче башкаласы - Болгар шәһәренең сакланып калган таш корылмалары мәгъмуриятында ачык күзәтелә.

Әл-Бәлхи, Әбу Гали Әхмәд ибне Рөстә, ибне Хаукал (Габделкасыйм Мөхәммәд) язган гарәп чыганаклары һәм ул шәһәрне шул заманнарда үз күзләре белән күргән башка сәяхәтчеләрнең язмалары буенча, Алтын Урда чорындагы Болгар шәһәре, үз масштабы белән заманының искиткеч зур шәһәрләренә тиң булган, анда урта гасырларга кагылышлы мөселман биналарының төрләре дә - мәчетләр, мәдрәсәләр, кәрвансарайлар, мунчалар, морзаларның затлы йортлары һ. б. булган.



Бу биналарның мәгъмуриятында бизәкләүгә зур әһәмият бирелгән. Бу турыда Болгар шәһәренең сакланып калган биналарындагы ташка (Җәмигъ мәчет, Кече манара) һәм алебастрга (Кара пулат) уеп кискән бизәкләр, фреска белән бизәлгән түшәмнәр (Ак пулат), майолика һәм мозаика белән капланган эчке диварлар, каберлекләр өсте (кәшәнәләр) сөйли. Соңгысының аерылып торган үзенчәлеге булып, Алтын Урданы Якын Көнчыгыш һәм Кече Азия мөселман мәгъмурияты белән якынайта торганы - бизәкләүдә күптөслелек. Харәземдәге һәм Иделнең түбәнге агымындагы шәһәрләрнең торак һәм җәмәгать биналарының (кәшәнәләр, мәчетләр һ. б.) тышкы һәм эчке диварлары, кабер өсте корылмалары, каннар (өй мичләре) төсле чинтакталар белән тышланган булган.

Алтын Урда шәһәрләре мөселман мәгарифе, әдәбияты, фәлсәфәсе үзәкләре булганнар, бу - белекле хаттатчыларның (каллиграф) ташка уелган эпитафия язуларында ачык чагылыш таба. Каберташларның очлары мәчет михрабларына охшатып, очланып килгән

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# АЯК АСТЫНДА

***лаһның әмеренә каршы килми торган, бары тик Аллаһ боерганны гына үти торган (зобанилар) фәрештәләр шул җәһәннәмнең сагында тора" ("Тәхрим (Харам)" сүрәсенең 6 нчы аяте)***, - ди.

Пәйгамбәрбез (сгв) дә үз хәдисләрендә: ***"Үз балаларыгызны хөрмәт итегез һәм яхшы тәрбия кылыгыз" (Ибне Мәҗә)***, - дигән.

Бар балалар да кеше табигате өчен хас булган Аллаһның Берлегенә ышанган хәлдә, иманлы булып дөньяга киләләр. Әбу Һөрәйрә (рг) тапшыруы буенча, Аллаһның рәсүле (сгв) әйткән: ***"Бар балалар да "фитрәт" белән туалар, аларны үз ата-аналары христиан, яһүди һәм мөшрик итә" (Бохари)***.

Фитрәт - бар кешеләрнең дә мөэмин-мөселман булып дөньяга килүен аңлата. Башкача әйткәндә, бала ана карынын ташлап киткән вакытта, аңа алдап тагылган күзаллаулардан, фикерләрдән азат булып тормыш ишеген ача. Аларның күңеле, ак кәгазь бите кебек чиста һәм пакь. Нәкъ менә аларның ата-аналары, аларда тирә-як мохит турында карашлар барлыкка китерәләр, аларга кайсы дин буенча китәргә икәнен сайлап алалар. Шуңа да, балаларының киләчәге өчен Аллаһ алдында җаваплылык нәкъ менә аларда.

Пәйгамбәрбез (сгв) дә үзенең дөньяга яратылуының сәбәбен хәдис-шәрифендә әйтә: ***"Мин әхлакны камилләштерү өчен Җиргә җибәрелгәнмен"***.

Әхлак тәрбиясенең мөһимлеге турында икенче бер хәдис тә дәлилли. Анда болай диелгән: ***"Үз балаларыгыз һәм өйдәгеләрегезне әхлакка өйрәтегез, аларны тәрбия кылыгыз" (Габдеразак)***.

Тиешле әхлак тәрбиясе бирү нәтиҗәсендә Аллаһка ышанып, диндар булып үскән бала кеше үзенең кылган бар гамәлләренә дә җаваплылык өчен һәрвакыт Аның контролен сизеп торачак. Балада әхлакый кыйммәтләр барлыкка килә башлаячак. Ул гадәттән тыш тыныч холкы, гаделлеге, тугрылыгы, үз ата-аналарына, туганнарына, дусларына тирән сөю хисе булуы белән аерылып торачак.

Аллаһы Тәгалә әйткән: ***"Ата-ананы канәгатьләндергәннәрнең барысы да - Аллаһны да канәгатьләндерер, аларның ачуын китергән бар әйбер һәм гамәлләр дә Аллаһның ачуын чыгарыр" (Сахих бине Хәббан, 2 нче бүлек, 172 нче бит, №429)***.

Кеше үз ата-анасына мәрхәмәтле һәм игелекле булырга тиеш. Аларны ихтирам итәргә һәм аларга карата кырыс, каты һәм усал мөнәсәбәттә булмаска тиеш. Алар белән ягымлы һәм йомшак сүзләр белән генә сөйләшергә кирәк. Аллаһы Тәгалә ата-анасына "уф" та диеп (ягъни, ялыктым инде мин сездән дип) әйтмәскә кушкан. Аллаһы Тәгалә ата-аналар белән хөрмәт белән аралашырга куша.

Имам Бохари һәм Мөслимнең хәдисләр җыентыгында шундый бер вакыйга турында сөйләнә.

Ничектер бервакыт, Аллаһның рәсүленә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) берәү килгән дә:

- Ий Аллаһның рәсүле, минем яхшы мөгамәлә кылуым өчен иң лаеклырагы кем? - дигән.

Ул:

- Синең әниең, - дигән.

Аннан соң бу кеше тагын сораган:

- Аннан кала кем?

Рәсүлебез әйткән:

- Синең әниең.

Бу кеше тагын:

- Ә аннан кем соң? - дип сорау биргән.

Ул тагын:

- Синең әниең, - дип җаваплаган.

Бу кеше тагын бер тапкыр аннан сораган:

- Ә аннан соң кем инде?

Шунда Пәйгамбәребез (сгв) аңа:

- Синең әтиең, - дигән.

Дин таләпләре буенча, балалар ата-аналарына үзләренең канәгать булмауларын тын алулары белән дә белдерергә тиеш түгелләр. Аллаһы Тәгалә ата-аналарның хәленә кереп яшәргә һәм: "Я Аллаһым, аларны рәхимшәфкатеңнән ташлама, алар мине мин кечкенә вакытта тәрбияләп үстерделәр бит", - дип, алар өчен Аллаһтан сорарга кушкан.

Пәйгамбәребезнең (сгв) хәдисләре дә ата-аналарга ихтирам күрсәтүнең кирәклеге турында сөйлиләр, аларны итагать итмәүдән, ялгыш рәнҗетүдән сак булырга чакыралар, һәм дә, моңа этәрүче нинди генә сәбәпләр булса да. Хәдистә: "Ата-аналарын хөрмәт итмәгән кеше, ул күпме генә изгелекләр эшләмәсен, барыбер Җәннәткә керми", - дип сөйләнә. Аллаһның рәсүле (сгв) дә: "Ата-анасы канәгать булган кешеләр алдында Җәннәт капкалары, канәгать булмаганнары алдында - Җәһәннәм капкалары ачылыр", - дип билгеләп киткән.

Ата-аналарыгызга карата булган гамәл һәм сүзләрегезне көн саен яхшырта барыгыз, аларның кәефен төшерә һәм аларга зыян эшли торган бар эшләрдән дә ерак торыгыз. Ата-аналарын югалткач кына, аларның үзләре өчен ни аңлатканнарын, никадәр дәрәҗәдә кадерле, кирәк булганнарын аңлаган күпме кеше бар бу дөньяда. Күп кешеләр, үз ата-аналарына, алар әле исән вакытта ук тиешле ихтирам, игътибар һәм хөрмәт, күңелләрендә булган бар сөю хисләрен дә күрсәтмәгәннәре өчен үкенәләр.

Ата-аналарына карата кылган гамәлләре өчен үкенүче кешенең җаны ничек ачы күз яшьләре белән елый, аларны инде башка күрмәячәгеңне, ул вакытларны, ул чакта мин бөтенләй башкача эшләр идем дип ниятләп, кире кайтарып булмаганлыкны аңлау коточкыч авыр. Тик соң инде, ул вакытлар үтеп киткән.

Ни өчен булганның чын бәясен бары тик югалткач кына аңлый башлыйбыз икән соң без?!

Ата-аналарыбызның догаларын һәммәбезгә дә алырга насыйп булса иде.

**Руслан хәзрәт МОРТАЗИН,**
**Татарстанның төньяк-көнчыгыш төбәге казые,**
**Актаныш Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы**

## Апанай мәчетендә никах мәҗлесләре үткәрелә

***Апанай мәчетендә никах мәҗлесләре үткәрәбез. Иң элек, әлбәттә, Апанай мәчетенә килеп никах көнен билгеләү кирәк. Никах бездә бушлай укытыла. Аны бер ай алдан да, бер атна кала да билгеләргә була. Хәтта иртәгә дигән көнне никах укытуны сорап килгән очракта да, вакыт һәм яшьләрнең никахка әзерлекләре тулысынча каралган булса, егет белән кызны кавыштырырга мөмкин. Әмма иң яхшысы - үзең теләгән сәгатьтә никахлашуны әйтеп, алдан билгеләнү.***

Мәчетебездә никах уку аерым бер бүлмәдә, килгән кунак һәм хәзрәт өчен куелган өстәл артында укыла. Никахта утызлап кеше катнаша ала. Килен белән кияү мулланың як-ягына утыртыла. Егетнең әти-әнисе һәм туганнары - егет ягына, ә кызныкылар кыз ягына тезелешә. Шуннан соң аларга Аллаһы Тәгалә, Аны гына мактау, Аңа гына иман китерергә тиешлеге һәм Аңардан гына сорау кирәклеге турында вәгазьләр укыла. Аннан ике шаһит билгеләнелә. Гадәттә, шаһит булып ике ир кеше сорала. Әгәр инде ике ир кеше булмый икән, ул вакытта бер ир кеше һәм ике хатын-кыз да шаһит ролен үти ала. Шаһитләргә үз вазифалары аңлатылып куела. Шуннан соң яшьләргә никахның асылы турында сөйләнә. Аңлатканнан соң, егет белән кызның әти-әнисе ризалыгы сорала. Әти-әнисе булмаганнарның исә якын туганнарыннан, вәзирләрдән ризалыкларын алабыз. Аннан кияү белән киленнең үз ризалыклары сорала. Алар үткән заман фигыль формасында: "Мин фәлән кызы фәләнне кабул итеп алдым", - дип әйтергә тиеш. Ахырдан, чәй табыны оештырырга була.

Теләге булганнар, Апанай мәчетенә килеп, никахка языла ала.

***БЕЗНЕҢ АДРЕС:*** **Казан шәһәре, Каюм Насыйри урамы, 27 нче йорт.**
**Тел.: 89600554329.**
**Чыганак: www.musulman.su.**



# Ислам мәдәниятендә Алтын Урда сәнгате

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

һәм уксыман арка формасында эшләнгәннәр, каймалар белән уратып алынганнар. Үзәкләрендә сигез таҗлы чәчәк кебек бизәк яки алты почмаклы йолдыз урнаштырылган. Кайбер каберташларда бу бизәкләр урынына гарәп язуы белән (сөлс һәм куфи язу төрләрендә) Коръәннән өзекләр төшерелгән.

Шәһәр, аның һөнәрчелек кярханәләре, күчмә кавем аксөякләренең зиннәтле бизәнү әйберләре, ат кирәк-яраклары, корал, тормыш-көнкүреш җиһазларына булган ихтыяҗларын үтәү өчен эшләгәннәр. Бу предметларның күбесе - кануни булып таралган билгеле бер сәнгати үрнәкләр нигезендә эшләнгәннәр. Бу, әлбәттә, беренче чиратта, декоративлык, һәм дә аеруча, бизәкләр төшерү, бигрәк тә "чәчәк стиле"ндәге орнаментлар белән аерылып торган зәргәрчелек, металлны нәфис эшкәртү сәнгатьләренә кагыла.

Алтын Урда зәргәрчеләре эшләгән зиннәтле җиһаз, кием-салым, бизәнү әйберләре Европа хакимнәре сарай кярханәләрендә эшләнгән зиннәтле әйберләргә дә йогынтысын салган. Татар осталары эшләгән зәргәрчелек сәнгатенең шедеврлары (мәсәлән, "Мономах бүреге") Россиянең патша регалийларына (Валеева-Сулейманова Г.Ф. Шапка Мономаха - имперский символ татарского происхождения // Золотоордынская цивилизация. Вып. 1. - Казань, 2008. - С. 22-29) кертелгәннәр. Алтыннан эшләнгән зиннәтле бизәнү әйберләре аеруча киң таралыш алган, аларның күпчелеге ислам мәдәниятендә үрнәккә әйләнеп киткән. Мәсәлән, гарәп язулары төшерелгән ярымайсыман эшләнгән алкалар, чәч асмалары, күкрәкчәләр, Коръән савытлары (аерым яисә чулпы белән бер төзмәләрдә), беләзекләр, йөзекләр һ. б. киң таралыш алган булган. Алар арасында Идел буе һәм Кырымның Алтын Урда чоры шәһәрләрендә казу эшләре башкарылган вакытта һәм аерым хәзинәләрдә табылган Коръән салына торган алтын савытларга аеруча игътибар итәргә кирәк. Алар шакмаклы, цилиндр һәм башка рәвешләрдәге тартмачыклар рәвешендә



эшләнгәннәр, алар җепкыр, уелма бизәкләр, төймә, уеп һәм басма ысулы белән эшләнгән үсемлек һәм эпиграфик орнамент белән дә бизәлгәннәр; фирүзә, ахак, энҗе, яшәм (яшма) асылташлары белән кырланганнар.

Гамәли бизәү сәнгатенең башка төрләреннән исә көнкүрештә коелган һәм коелмый эшләнгән керәч савыт-сабаларны (тәлинкәләр, чынаяклар, яктырткычлар, шәмдәлләр һ. б.) күрсәтергә була. Массакүләм эшләнгән әйберләр арасында Идел буе Болгарстанының монголгача дәверендәге сызыклы орнаментлы, үзенчәлекле тәбәнәк формалы, купшы керәч сәнгате традицияләре дәвам ителә. Сирәк кенә хайван гәүдәле, тоткалы, авызлы савыт-сабалар да очрый. Формасы һәм орнаментлары бар мөселман дөньясындагы керәч сәнгате үсеше агымы өчен хас. Бу - керәч әсәрләрен бизәүдә гарәп язуларын, мөселман сәнгатенең бизәү системасын һәм төсләр палитрасын куллануга кагыла.

Алтын Урда чорында сәнгать теле шактый зур үзгәрешләр кичерә, ул мөселман сәнгате үсешенең гомуми закончалыкларын чагылдыра башлый. Алар сурәтләүнең кабул ителгән кануннарында чагылалар. Сәнгать белемендә "хәлифәт кануны" дигән атама алган мөселман кануны, сәнгати һөнәрчелек төре белән туры бәйлелектә булган һәм сурәтләү чараларын хаттатчылык һәм мөселман сәнгатенә хас бизәкләре белән якынлаштыруны үзмаксат итеп куйган.

Шуңа да, Алтын Урда сәнгатендә орнаментта "чәчәк стиле" киң таралыш алган. Болгар орнаменты өчен төрле геометрик төзелмәләр, шул исәптән, симметрия, үзәкле композицияләр, бизәлештә геометрияле куфи язуын куллану белән мавыгу Алтын Урда чорына кадәр үк хас булган. Моның кануни нәтиҗәсе буларак, Алтын Урда сәнгатендә Шәрыкның мөселман сәнгатендәге кебек үк, орнаментларда арабеск дәрәҗәсендәге бизәкләр күренә башлый һәм гарәп язуыннан торган орнамент киң таралыш ала.

Үзара кабатланучы хәреф һәм сүзләрдән торган гарәп язулары куллану һәм аның нигезендә эпиграфик орнаментның барлыкка килүе - гамәли сәнгатьнең киң даирәсен чолгап ала. Бу - каберташларга уелган бизәкләр, җиз йозак һәм көзгеләр, керәч әсәрләре (көнкүреш керәч һәм конус рәвешендәге чүлмәкләр), бизәнү әйберләре - миниатюр Коръән салу савытлары, балдаклар-йөзекләр, шул исәптән, асылташлар белән бизәлгән йөзекләр, беләзекләр һ. б. Болардан тыш, гарәп язуы мәгъмурият һәйкәлләрендәге уелма декорларда да, монументаль-декоратив бизәкләүнең кайбер төрләрендә (майолика, мозаика, алебастрдан коеп эшләү) дә кулланыла. XIII гасыр ахыры - XIV гасырдан башлап, гарәп язулары орнаментның бер өлешенә әйләнә, алар "чәчәкле куфи" яки "чәчәкле сөлс" дип атала торган нәкыш бизәкләр булып үсеш алалар. Бормалы каллиграфик язулар каберташларда, беләзекләрдә күренә башлый. Эпиграфик орнамент үзенең үсеш процессында абстракт эчтәлекле гомуми бер нәфис сурәткә әйләнә.

Мәкаләнең чикләнгән кысаларында Алтын Урдадагы барлык сәнгать әсәрләренең күптөрлелеген, аларның ислам дөньясы сәнгате белән булган гомумилеген колачлап алу мөмкин түгел. Шуңа да карамастан, аларга хас булган форма һәм мотивларны тарихи-чагыштырма өйрәнү - Алтын Урда сәнгатенең ислам эстетикасы чикләрендә камилләшү процессын ачыклый. Ә бу исә Алтын Урда сәнгатен ислам мәдәниятенең билгеле бер төбәк һәм җирле сәнгать үзәкләре аерымлыкларын саклап калган (безнең көннәргә җиткергән) үзенчәлекле бер юнәлеше дип исәпләргә мөмкинлек бирә.

***Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,***
***сәнгать фәннәре докторы,***
***Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтының***
***баш фәнни хезмәткәре***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 24.11.12 | 7:07 | 8:37 | 13:02 | 15:16 | 16:23 | 17:53 |
| Якшәмбе | 25.11.12 | 7:09 | 8:39 | 13:02 | 15:15 | 16:21 | 17:51 |
| Дүшәмбе | 26.11.12 | 7:11 | 8:41 | 13:02 | 15:14 | 16:20 | 17:50 |
| Сишәмбе | 27.11.12 | 7:13 | 8:43 | 13:02 | 15:13 | 16:19 | 17:49 |
| Чәршәмбе | 28.11.12 | 7:14 | 8:44 | 13:02 | 15:13 | 16:18 | 17:48 |
| Пәнҗешәмбе | 29.11.12 | 7:16 | 8:46 | 13:02 | 15:12 | 16:17 | 17:47 |
| Җомга | 30.11.12 | 7:18 | 8:48 | 13:02 | 15:11 | 16:16 | 17:46 |
| Шимбә | 1.12.12 | 7:19 | 8:49 | 13:02 | 15:11 | 16:15 | 17:45 |

# Сөйләм әдәбе

*(Ахыры. Башы газетабызның 16 ноябрь (№20) санында.)*

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) дин һәм шәригать өлкәсендә җибәрелгән ниндидер ялгышлар турында әйтеп китәргә теләсә, бер вакытта да ялгышлык җибәрүчеләрнең исемен атамаган, ә бәлки: «Нишләп кайберәүләр андый гамәлләр эшли, ни турында уйлыйлар икән алар?» – дип әйтә торган булган. Мөхәммәд пәйгәмбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) шулай ишарәләр белән кисәтүләр ясаган, чөнки ул кешеләр турында начар сөйләргә яратмаган.

Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) әдәбе шулай булган: әгәр кемнең дә булса ялгышын әйтергә кирәк булса, ул бу кеше белән аның янына килеп үзе сөйләшкән, бар халык алдына чыгып кычкырмаган.

Бүгенге көндә кайберәүләр өчен үзара итагатьле аралашу күтәрә алмаслык бер йөккә әйләнде. Хәзерге заман кешеләре белән матур гына итеп әңгәмә алып баручы башка кеше аларны бик тиз йөдәтеп бетерә һәм аның белән аралашу аларга эчпошыргыч булып тоела башлый. Бу кешеләр, ни кызганыч, әңгәмәдәшең белән итагатьле итеп аралашуның Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сөннәте икәнен аңлап бетермиләр, гел истән чыгаралар.

Ә җәмгыятьнең кайбер әгъзаларында исә килешсез, әшәке тиргәшү сүзләре куллану, гәптәшеңне кимсетү, сүгенү (хәтта сәлам бирешүдә дә) аларның эчке ихтыяҗына туры килә торган сөйләшү стиленә әйләнде.

Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!), бервакыт, Җәбир (Аллаһ аңардан риза булсын!) исемле үзенең бер сәхабәсенә килгән һәм тегесе Пәйгамбәрдән (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): “Ий Аллаһның Рәсүле, миңа күрсәтмәләреңне бир, мине нигә дә булса өйрәт”, – дип сораган. Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аңа: «Беркемне дә, беркайчан да кимсетмә!» – дип җавап биргән. Шуннан Җәбир (Аллаһ аңардан риза булсын!) үзе: «Аллаһ белән ант итеп әйтәм, бу сүзләрдән соң минем бер генә кешене дә, хатын-кызмы ул, ир-атмы, иректә кешеме, колмы, хәтта җанварларны да кимсеткәнем булмады», – дип сөйли торган булган. Җәбир (Аллаһ аңардан риза булсын!) Пәйгамбәребезне (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) бер сүздән үк аңлаган һәм аның күрсәтмәләре буенча гамәл кыла башлаган, аннан соң үз гомерендә бер генә тапкыр да үз сөйләмендә юньсез сүзләр кулланмаган.

Бервакыт бер хатын-кыз үзе атланып барган дөясен каргый икән. Шунда Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): «Бу дөядән аның йөген алыгыз да, аны иректә калдырыгыз. Каргалган дөягә безнең арада барырга юл куймагыз», – дигән. Һәм бу дөя үз көенчә бара башлаган. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аны кәрван арасында калдырмаска кушкан.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) әйткән: ***“Кайвакыт шундый очрак та булырга мөмкин: ниндидер бер кеше иптәшләрен көлдерер өчен генә, кирәкмәгән кайбер сүзне әйтеп җибәрергә мөмкин, ләкин ул, үзенең шул яман сүзе аркасында, Иләк йолдызлыгына кадәр тирәнлектәге җәһәннәмгә чумарга да мөмкин”.***

Кайвакыт кеше нинди дә булса кирәкмәгән бер сүз әйтеп, иптәшләрен көлдерергә тели. Тик үзенең килешсез бу сүзләре белән ул Аллаһ тарафыннан күндерелгән әдәпне бозарга мөмкин. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) башка кешеләрнең күңелен төшерә торган сүзләр куллануны тыйган. Андый сүзләр куллану – Аллаһ Үзенең колларын нинди сәләтләр белән бүләкләвен бу сөйләүченең онытып бетергәнлегенә дәлил.

Хәзерге вакытта андый сүзләрне тискәре (негатив), диләр. Чөнки алар җәмгыять әгъзаларының күңелен төшерә, кәефләрен кыра, кешеләрне караңгыга, шомлыга, негативка карарга мәҗбүр итә. Нәтиҗәдә, кешеләрнең эчке дөньясы, аның чисталыгы һәм тынычлыгы бетә.

Иң әйбәте – матур һәм яхшы сүзләрне генә куллану. Бу – Сөннәт таләпләрен үтәү дип атала. Син үз сөйләмеңне шулай камилләштергәч, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) артыннан баручы кешегә әйләнәчәксең. Ул вакытта син кем белән генә сөйләшсәң дә – гаиләңдәме, чиновник беләнме яки кечкенә балалар беләнме – син күңелеңә якын кеше белән аралашачаксың.

*«Һәр савыт, аның эчендә ни бар, шуны сибәр, ә кеше теле – аның күңелендә ни бар, шуны чәчәр»,* – диләр.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) иң пакь күңелле кеше булган, шуңа аның сөйләме төзек һәм чиста булган. Һәм дә ул безгә өлге булып тора.

Коръәндә (мәгънәсе): **«*(Рәсүлуллаһ)* син әйт:**

**– Әгәр Аллаһны сөйсәгез, миңа иярегез (Исламны кабул итегез). Аллаһ та сезне сөяр вә гөнаһларыгызны ярлыкар, – диген. Аллаһ мәрхәмәтле ярлыкаучы»** («әл-Гыймран (Гыймранның гаиләсе)» сүрәсенең 31 нче аяте), – диелгән.

Без үзебезнең сөйләмебездә генә түгел, ә күңел халәтебездә, гамәлләребездә дә пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) артыннан баруның мөһимлеген аңларга тиешлебез.

**Фәһим хәзрәт ӘХМӘТҖАНОВ,**
**Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәге казые,**
**Чүпрәле районы имам-мөхтәсибе;**

**Нияз САБИРҖАНОВ,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге белгече**

«**Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 21 (164) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9426.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 22 ноябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).